ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КАРГАЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАРЫ

№ 30/2 2022 елның 29 декабре

«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Каргалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендәге муниципаль милекне хосусыйлаштыру тәртибен раслау турында» 2019 елның 24 сентябрендәге 78/1 номерлы Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Каргалы авыл җирлеге Советының карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында «Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында»2022 елның 5 декабрендәге 512-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Чистай шәһәр прокурорының федераль законнарны бозуларны бетерү турында 2022 елның 21 декабрендәге 02-08-03-2022 номерлы күрсәтмәсен карап, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Каргалы авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Каргалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендәге муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының 2019 елның 24 сентябрендәге 78/1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Каргалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендәге муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру тәртибен раслау хакында» Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Каргалы авыл җирлеге советы карары белән расланган Нигезләмәгә, 8.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:
«8.5. Ачык тәкъдим аша сатуда катнашу өчен, дәгъва итүче алдан түләүне түбәндәге күләмдә кертә:

Муниципаль милекне сату турында мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән һәм 100 миллион сум һәм аннан да күбрәк суммада күрсәтелгән башлангыч бәянең 20 проценты;

Муниципаль милекне сату турында мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән һәм 100 миллион сумнан ким булган башлангыч бәянең 10 проценты.

Мәгълүмат хәбәрендә күрсәтелгән счетка алдан түләү керүне раслаучы документ әлеге счеттан өземтә булып тора.».

2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә игълан итәргә һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында www.chistopol.tatarstan.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Каргалы авыл җирлеге Советының Законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Каргалы авыл җирлеге

башлыгы ________ М.А. Заһидуллин